КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 февраль г.Казань № 98

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары keremнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына теркәлгән кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1041 нче; 2019 ел, 26 ноябрь, 1080 нче; 2020 ел, 3 февраль, 69 нчы; 2020 ел, 14 апрель, 281 нче; 2020 ел, 23 июнь, 521 нче, 2020 ел, 04 ноябрь, 991 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) теркәлгән кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

I бүлектә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

1) әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы исклар буенча түләүләр, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны (махсус саклана торган табигать территорияләрендәге әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыяннан тыш) ирекле рәвештә каплаганда түләнелә торган, муниципаль берәмлек бюджетына керергә тиешле түләүләр;

2) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (урманнардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

3) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (урманнардан рөхсәтсез файдаланган, авыл хуҗалыгын алып бару өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен бозган, урман ресурсларын бетергән өчен штрафлар);

4) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (агачларны законсыз кискән, урман утыртмаларына зыян салган яки урманнардагы агачларны, куакларны, үрмәле үсемлекләрне рөхсәтсез казып алган өчен штрафлар);

5) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (урманнарда санитария куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

6) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар);

7) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (Россия Федерациясе субъекты территориясендә урман янгыннарын сүндерүнең җыелма планы белән күздә тотылган чараларны үтәмәгән өчен штрафлар);

8) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8 бүлегендә билгеләнгән, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләренең вазыйфаи затлары тарафыннан салына торган административ штрафлар (башка штрафлар);

9) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән административ штрафлар, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан җайга салына торган идарә тәртибенә каршы административ хокук бозулар өчен (дәүләт күзәтчелеген (контролен) гамәлгә ашыручы органның (вазыйфаи затның), муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы органның (вазыйфаи затның), органның (вазыйфаи затның) законлы күрсәтмәсен (карарларын, карарларын) вакытында үтәмәгән өчен, федераль законнар нигезендә дәүләт күзәтчелеген (вазыйфаи затны) гамәлгә ашыруга вәкаләтле оешмага;

10) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән идарә итүгә каршы административ хокук бозулар өчен җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (белешмәләрне (мәгълүматны) тапшырмаган өчен штрафлар);

11) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән идарә итүгә каршы административ хокук бозулар өчен җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (бүтән штарфлар);

12) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20 бүлегендә билгеләнгән административ хокук бозулар өчен, җәмәгать тәртибенә һәм җәмәгать иминлегенә яный торган, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган, административ штрафлар (бүтән штарфлар);

13) авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, дәүләт яки муниципаль предприятиеләр йә дәүләт яки муниципаль учреждениеләр тарафыннан төзелгән сервитутны билгеләү турындагы килешүләр буенча түләү;

14) авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә һәм эш итү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган һәм гражданнарга яки юридик затларга бирелмәгән җир кишәрлекләренә карата вәкаләтле органның ачык сервитут билгеләү турындагы карары белән күздә тотылган ачык сервитут өчен түләү (дәүләт хакимияте органнарыннан (дәүләт органнарыннан), җирле үзидарә органнарыннан (муниципаль органнардан), бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнарыннан һәм казна учреждениеләреннән тыш).»;

15) 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны түләп бетерү исәбенә керә торган 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча муниципаль берәмлек бюджетына күчерелергә тиеш акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) керемнәр (муниципаль берәмлекнең финанс органы бурычны аерым исәпкә алу турында карар кабул иткән очракта, муниципаль юл фондын төзүгә җибәрелә торган керемнәрдән, шулай ук башка түләүләрдән тыш, муниципаль районнар бюджетларының керемнәре)

4 пунктта:

2 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктчада «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 19 пунктчасында «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның 8 пунктчасында «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның 5 пунктчасында «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның 14 пунктчасында «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «2020 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган» сүзләрен «2019 елда гамәлдә булган» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

1) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән идарә итүгә каршы административ хокук бозулар өчен җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (белешмәләрне (мәгълүматны) тапшырмаган өчен штрафлар);

2) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19 бүлегендә билгеләнгән идарә итүгә каршы административ хокук бозулар өчен җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган административ штрафлар (бүтән штарфлар);

3) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20 бүлегендә билгеләнгән административ хокук бозулар өчен, җәмәгать тәртибенә һәм җәмәгать иминлегенә яный торган, җәмәгать судьялары, балигъ булмаганнар эшләре

һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре тарафыннан салына торган, административ штрафлар (бүтән штарфлар).».

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин